ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ**
**03.04.2019**

Зеленодольск
шәһәре

**БОЕРЫК**
**№ 03-04-22**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты хезмәткәрләренә муниципаль хезмәт стажын билгеләү буенча комиссия нигезләмәсен һәм составын раслау турында

Муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы кодексы нигезендә, кадрлар үзгәрүенә бәйле рәвештә:

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты хезмәткәрләренә муниципаль хезмәт стажын билгеләү комиссиясе турында нигезләмәне 1 нче кушымта нигезендә расларга.
2. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты хезмәткәрләренә муниципаль хезмәт стажын билгеләү буенча комиссия составын 2 нче кушымта нигезендә расларга.
3. «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты хезмәткәрләренә муниципаль хезмәт стажын билгеләү буенча нигезләмәне һәм комиссияне раслау турында» 2015 елның 6 февралендәге ОД-10 номерлы боерыгы, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты хезмәткәрләренә муниципаль хезмәт стажын билгеләү буенча нигезләмәне һәм комиссияне раслау турында» 2015 елның 6 февралендәге ОД-10 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 30 июнендәге ОД-38 номерлы, боерыгы үз көчләрен югалткан дип танырга.
4. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тортны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче Д.А. Сапожников

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 03 апрелендәге 03-04-2022 номерлы боерыгына
1 нче кушымта

\

**Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты хезмәткәрләренә муниципаль хезмәт стажын билгеләү буенча комиссия**
**НИГЕЗЛӘМӘ**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Комиссия Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты хезмәткәрләренә тиешле еллар эшләгән өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә билгеләү өчен муниципаль хезмәт стажын билгеләү буенча (алга таба - Комиссия) Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты хезмәткәрләренә тиешле еллар эшләгән өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмәләр алу хокукын бирә торган стаж билгеләү һәм карарлар кабул итү мәсьәләләрен карау өчен булдырылган даими эшләүче коллегиаль орган булып тора.

1.2. Комиссия үз эшчәнлегендә 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең тикшерү-хисап органнары рәисләренә, муниципаль хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләү чыгымнарын финанслау нормативлары турында» 182 номерлы карарына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 30 мартындагы «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмаган бюджет өлкәсендәге аерым оешмалар хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 195номерлы карарына, Зеленодольск муниципаль районы Советының 2017 елның 12 октябрендәге 240 номерлы карары белән (алга таба үзгәрешләре һәм өстәмәләр белән) расланган, Зеленодольск муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 24 апрелендәге «Зеленодольск муниципаль районында бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмаган бюджет өлкәсендәге аерым оешмалар хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 976 номерлы карарына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

1.3. Комиссия үз эшен карарлар кабул иткәндә коллегиальлек һәм бәйсезлек принциплары нигезендә төзи.

1.4. Комиссия составы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты боерыгы белән раслана.

1.5. Тиешле еллар эшләгән өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә алу хокукын бирә торган гомуми эш стажын билгеләү өчен төп документ булып хезмәт кенәгәсе, хәрби билет, гражданның хезмәт эшчәнлеген раслый торган башка документлар тора.

1.6. Тиешле еллар эшләгән өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмәләр алу хокукын бирә торган гомуми эш стажы 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 29,30 ст. һәм Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары нигезендә исәпләп чыгарыла.

1.7. Комиссия вәкаләтләре чикләрендә кабул ителгән карар өчен җаваплылык комиссия рәисенә йөкләнә.

## 2. Комиссиянең бурычлары һәм функцияләре

2.1. Комиссиянең төп бурычлары түбәндәгеләр:

- Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетында билгеләнгән Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфасын башкаручы муниципаль хезмәткәрләргә тиешле елларны эшләгән өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә билгеләү мәсьәләләре буенча Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарын үтәүне тәэмин итү;
- муниципаль хезмәт вазыйфаларына кертелмәгән һәм Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты эшчәнлеген матди-техник һәм оештыру ягыннан тәэмин итүне гамәлгә ашыручы хезмәткәрләргә тиешле еллар эшләгән өчен хезмәт хакына айлык өстәмә түләү билгеләү.

2.2. Комиссия үзенә йөкләнгән бурычларны гамәлгә ашыру максатларында түбәндәге функцияләрне башкара:

2.2.1. Муниципаль хезмәткәрләргә һәм вазыйфа биләүче хезмәткәрләргә муниципаль хезмәт вазыйфаларына кертелмәгән һәм Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты эшчәнлеген матди-техник һәм оештыру ягыннан тәэмин итүне гамәлгә ашыручы вазыйфаи окладка айлык өстәмә билгеләү мәсьәләләре буенча карарлар кабул итә.

2.2.2. Кирәкле очракларда экспертиза уздыруны, экспертлар-юристларны җәлеп итеп, тиешле өстәмәләр уздыруны оештыра.

## 3. Комиссиянең хокуклары һәм бурычлары

3.1. Комиссия түбәндәгеләргә хокуклы:

3.1.1. Күрсәтелгән өстәмәләрне билгеләүнең нигезлелеген һәм аларны түләүнең үз вакытында башкарылуын тикшереп торырга.

3.1.2. Тиешле еллар эшләгән өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә билгеләү һәм түләү тәртибе буенча һәм әлеге мәсьәләләрне карау процедурасы буенча аңлатмалар бирергә.

3.2. Комиссия түбәндәгеләргә бурычлы:

3.2.1. Аларны теркәгәннән соң бер ай эчендә өстәмә билгеләү буенча алынган гаризаларны һәм шикаятьләрне карарга.

3.2.2 Комиссия компетенциясе чикләрендә ачыкланган хокук бозуларны бетерү чараларын күрергә.

## 4. Комиссия утырышларын әзерләү һәм уздыру тәртибе

4.1. Комиссия эше җитәкчелеген Комиссия рәисе, ә ул булмаганда аның урынбасары башкара.

4.2. Комиссия секретаре Комиссия эшен оештыруны тәэмин итә:

- Комиссия рәисе карары буенча, мәсьәләләрне Комиссия каравына чыгара;
- Комиссия утырышы өчен материаллар әзерли;
- Комиссиянең утырышлар беркетмәләрен рәсмиләштерә;
- утырыш башланганчы өч көннән дә соңга калмыйча, Комиссия әгъзаларына алда булачак утырыш турында хәбәр итә;
- Комиссия әгъзалары игътибарына Комиссия утырышы башланырга өч көн кала тәкъдим ителгән материаллар турында мәгълүмат җиткерә;
- Комиссия утырышлары беркетмәләрен төзи һәм саклый;
- өстәмәләр билгеләү буенча мәгълүматларны исәпкә алып бара;
- өстәмәләр дәрәҗәсенең үз вакытында үзгәрүен күзәтә;
- үз компетенциясе чикләрендә башка оештыру-техник функцияләр башкара.

## 5. Комиссия эше регламенты

5.1. Стаж билгеләү комиссиясе кирәк булган саен, кварталга кимендә бер тапкыр җыела. Комиссия утырышлары, әгәр аларда кимендә 2/3 әгъзасы булса, тулы хокуклы дип санала.

5.2. Карар Комиссия утырышында катнашучыларның тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Тавышлар тигез бүленгән очракта, хәлиткеч тавыш Комиссия рәисендә була.

5.3. Комиссия карары беркетмә белән рәсмиләштерелә, ул Комиссиянең барлык әгъзалары тарафыннан имзалана һәм Комиссия рәисе тарафыннан раслана.

5.4. Комиссия әгъзалары, карар белән килешмәгән очракта, беркетмәдә аерым фикер белдерергә хокуклы.

5.5. Комиссия утырышы беркетмәсе, өч көн эчендә Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә хезмәткәрләргә тиешле еллар эшләгән өчен өстәмә түләүләр билгеләү һәм түләү өчен тапшырыла.

5.6. Өстәмәләрне билгеләү Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты боерыгы нигезендә башкарыла.

## 6. Комиссия эшчәнлегенә контроль һәм Комиссия карары өчен җаваплылык

6.1. Комиссия эшчәнлеген тикшерүне Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе башкара.

6.2. Комиссия вәкаләтләре чикләрендә кабул ителгән карар өчен җаваплылык Комиссия рәисенә йөкләнә.

6.3. Тиешле еллар эшләгән өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә билгеләү яисә шушы өстәмәнең күләмен билгеләү өчен муниципаль хезмәт стажын билгеләү мәсьәләләре буенча индивидуаль бәхәсләр законда билгеләнгән тәртиптә карала.

## 7. Үзгәрешләр һәм өстәмәләр

7.1. Әлеге Нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты боерыгы белән кертелә.

## 8. Эшчәнлекне туктату

8.1. Комиссия эшчәнлеге Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты боерыгы нигезендә туктатыла.

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2019 елның 03 апрелендәге
03-04-2022 номерлы боерыгына
2 нче кушымта

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты хезмәткәрләренә муниципаль хезмәт стажын билгеләү комиссиясе составы

| | |
|---|---|
| Сапожников Дмитрий Аркадьевич | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе; |
| Старостин Александр Владимирович | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары, комиссия рәисе урынбасары; |
| Муллинова Татьяна Александровна | Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының кадрлар сәясәте бүлеге баш белгече, комиссия секретаре (килешү буенча); |
| Комиссия әгъзалары: | |
| Яковлева Марья Николаевна | Зеленодольск муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе (килешү буенча); |
| Перова Елена Александровна | Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының кадрлар сәясәте бүлеге башлыгы (килешү буенча); |
| Мөхәммәтханов Тимур Фәрит улы | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлеге башлыгы (килешү буенча); |

| | |
|---|---|
| Пименова Наталья Николаевна | «Зеленодольск муниципаль районы юридик бюросы» муниципаль казна учреждениесе җитәкчесе (килешү буенча). |